БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» 08 2022 ел № 261

**Мәктәп автобусының «Кече Лызи – Зур Лызи-2 -Кече Лызи» яңа маршрутын ачу турында**

«Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 3 августындагы 400 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф учреждениеләре укучыларын транспорт белән имин һәм өзлексез йөртүне тәэмин итү максатларында, мәктәп автобусларының маршрутларын тикшерү комиссияләре актлары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Мәктәп автобусының «Кече Лызи – Зур Лызи-2 - Кече Лызи» яңа маршрутын ачарга.

2. Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасына мәктәп автобусының «Кече Лызи – Зур Лызи-2 - Кече Лызи» яңа маршрутын ачуны финанслауны тәэмин итәргә.

3. «Районара юл-төзелеш идарәсе-1» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә (ООО «МДСУ -1») әлеге маршрутлар буенча автомобиль юлларын һәм юл хәрәкәтен җайга салуның техник чараларын тиешенчә карап тотуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Балтач районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ бүлегенә мәктәп автобуслары юлында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов